КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 10 июнь г.Казань № 543

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы социаль яклау дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 482 нче; 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы; 2018 ел, 16 ноябрь, 998 нче; 2019 ел, 17 июль, 594 нче; 2019 ел, 28 август, 715 нче; 2019 ел, 22 октябрь, 952 нче; 2019 ел, 6 декабрь, 1110 нчы; 2021 ел, 2 апрель, 212 нче; 2021 ел, 20 июль, 605 нче; 2021 ел, 26 июль, 654 нче, 2021 ел, 21 октябрь, 990 нчы, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренәхезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмаларының һәм социаль яклау дәүләт учреждениеләренең мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Аена база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификация-ле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программа-лары буенча Урта һөнәри белем, урта звено бел-гечләрен әзерләү программала-ры буенча Урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификациясен биреп раслана торган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗәдәге укыту буенча ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квали-фикация баскычы | Тәрбияче ярдәмчесе | 13 617 | - | - |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту буенча ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квали-фикация баскычы | Кече тәрбияче | 13 700 | 14 000 | - |
| Педагогик хезмәткәр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квали-фикация баскычы | Хезмәт буенча инструктор | - | 14 480 | 16 700 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Физик культура буенча инструктор | | | |
| | Музыка буенча җитәкче | | | |
| Икенче квалификация баскычы | Инструктор-методист | - | 14 487 | 16 720 |
| | Концертмейстер | | | |
| | Социаль педагог | | | |
| Өченче квалификация баскычы | Тәрбияче | - | 14 493 | 16 732 |
| | Методист | | | |
| | Педагог-психолог | | | |
| | Өлкән инструктор-методист | | | |
| Дүртенче квалификация баскычы | Өлкән тәрбияче | - | 14 495 | 16 736 |
| | Өлкән методист | | | |
| | Укытучы | | | |
| | Укытучы-дефектолог | | | |
| | Укытучы-логопед (логопед) | | | |

Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларның, психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар өчен интернат-йортларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре өчен база (вазыйфаи) окладка тармакның өстенлек коэффициенты кулланыла.

Тармакның өстенлек коэффициенты зурлыгы:

педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренең беренче - өченче квалификация баскычлары хезмәткәрләре өчен - 1,4;

педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренең дүртенче квалификация баскычы хезмәткәрләре өчен - 1,5.

Мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең педагогик хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре өчен база (вазыйфаи) окладка тармакның өстенлек коэффициенты кулланыла.

Тармакның өстенлек коэффициенты зурлыгы:

педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренең беренче - өченче квалификация баскычлары хезмәткәрләре өчен - 1,34;

педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренең дүртенче квалификация баскычы хезмәткәрләре өчен - 1,44.

Күрсәтелгән коэффициентларны база окладына карата куллану яңа база окладын барлыкка китерә һәм компенсация характерындагы һәм кызыксындыру максатыннан түләүләрне исәпләп чыгарганда исәпкә алына.»;

6.3 пунктның 6.3.7 пунктчасында «акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларында» сүзләрен «психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында» сүзләренә алмаштырырга;

25 таблицаның «Акылга зәгыйфь балалар өчен интернат балалар йортлары, физик җитешсезлекләре булган балалар өчен интернат йортлар» юлының 1 нче графасында «Акылга зәгыйфь балалар өчен интернат балалар йортлары" сүзләрен "Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында» сүзләренә алмаштырырга;

9.3 пунктның өченче абзацында «акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларында» сүзләрен «психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада таблица исеменең 6 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йорты;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

нумерация исемендә «халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре» сүзләрен «эшче һөнәрләренең һәм гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре - халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт социаль яклау учреждениеләре җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Акылга зәгыйфь балалар өчен балалар интернат йорты» сүзләрен «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йорты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтаның нумерация исемендә «халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре» сүзләрен «эшче һөнәрләренең һәм гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре - халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт социаль яклау учреждениеләре җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Хезмәтне саклау буенча кече белгеч | урта һөнәри белем - хезмәтне саклау өлкәсендә урта звено белгечләрен әзерләү программалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү | хезмәт буенча техник | 13 617 |
| Хезмәтне саклау буенча белгеч | урта һөнәри белем - хезмәтне саклау өлкәсендә урта звено белгечләрен әзерләү программалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү; хезмәтне саклау өлкәсендә югары белем - бакалавриат яисә югары белем (профильсез) - бакалавриат һәм өстәмә һөнәри белем - һөнәри яңадан әзерлек программалары; урта һөнәри белем булган очракта хезмәтне саклау өлкәсендә кимендә өч ел стаж | инженер; хезмәтне саклау буенча инженер | 14 911 |
| Хезмәтне саклау буенча баш (әйдәүче) белгеч | хезмәтне саклау өлкәсендә югары белем - бакалавриат яисә югары белем (профильсез) - бакалавриат һәм өстәмә һөнәри белем - һөнәри яңадан әзерлек программалары; югары белем булганда хезмәтне саклау өлкәсендә кимендә өч ел яки урта һөнәри белем булган очракта хезмәтне саклау өлкәсендә кимендә дүрт ел стаж | 1 категория инженеры; 1 категория хезмәтне саклау инженеры | 15 301 |
| Гражданнар оборонасы буенча белгеч Гадәттән тыш хәлләрдә яклау буенча белгеч Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә яклау буенча белгеч | урта һөнәри белем - урта звено белгечләрен әзерләү программалары яисә урта һөнәри белем (профильсез) - урта звено белгечләрен әзерләү программалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү - квалификация күтәрү | иженер | 14 911 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Граждан яклавы буенча белгеч | программалары, һөнәри яңадан әзерләү программалары | | |
| Гражданнар оборонасы буенча әйдәп баручы белгеч Гадәттән тыш хәлләрдә яклау буенча әйдәп баручы белгеч<br>Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә яклау буенча әйдәп баручы белгеч<br>Граждан яклавы буенча әйдәп баручы белгеч | югары белем - бакалавриат яисә югары белем (профильсез) - бакалавриат һәм өстәмә һөнәри белем - һөнәри яңадан әзерлек программалары; | 2 категория инженер | 15 104 |
| Гражданнар оборонасы буенча баш белгеч<br>Гадәттән тыш хәлләрдә яклау буенча баш белгеч<br>Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә яклау буенча баш белгеч<br>Граждан яклавы буенча баш белгеч | югары белем - бакалавриат яисә югары белем (профильсез) - бакалавриат һәм өстәмә һөнәри белем - квалификация күтәрү программалары, һөнәри яңадан әзерлек программалары;<br>һөнәри эшчәнлек юнәлеше буенча кимендә өч ел стаж | 1 категория инженер | 15 301». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин